Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының илле беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

26 февраль, 2025 ел № 382

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район башлыгының Мактау грамотасы һәм Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район башлыгының Мактау грамотасы һәм Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 24 ноябрендәге 122 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район башлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район башлыгының Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына
26 февраль, 2025 ел № 382

Кушымта № 3
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район башлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәгә

# Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район башлыгының Мактау грамотасы тасвирламасы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район башлыгының Мактау грамотасы (алга таба - Мактау грамотасы) А3 форматы бланкыннан тора.

Бланк берьяклы сурәткә ия, тыгыз, тонык кәгазьдә әзерләнә. Бланк фоны соры төстә. Бланк периметры буйлап 15 миллиметр киңлектәге геометрик паттерн рәвешендәге орнамент урнашкан.

Бланкның өске өлешендә уртадан 10 миллиметр арада Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы гербы урнашкан, аның зурлыгы 35*30 миллиметр тәшкил итә, ул күптөсле мөһер белән башкарылган (яшел кырлы кара кызыл битнең өске өлешендә - алтын кувшин, аның өстендә алтын әтәч тора, аяклары янында койрыклары кыскартылып утырган һәм әйләнеп киткән ике көмеш чәшке тотып тора).

Вертикаль буенча 30 миллиметр арада Питрәч муниципаль районы гербының сул һәм уң ягында өч юлда «ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» һәм «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПИТРӘЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» сүзләре урнашкан. Текст блоклары кара төстә эшләнгән, хәрефләрнең биеклеге 5 миллиметр.

Бланкның уң чигеннән горизонталь буенча 52 миллиметр һәм югары чигеннән вертикаль буенча 57 миллиметр ераклыкта «ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА» дигән язу урнашкан. Хәрефләрнең биеклеге - 15 миллиметр, озынлыгы - 250 миллиметр. Язу кызыл төстә эшләнгән.

Астарак кара төстәге 10 миллиметр (баш), 5 миллиметр (юл) биеклектәге хәрефләр белән бүләкләнүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазифасы басыла.

Тагын да түбәнрәк 10 миллиметрга кара төстәге 5 миллиметр (баш) һәм 3 миллиметр (юл) биеклектәге хәрефләр белән бүләкләнүче казанышларының кыскача тасвирламасы басыла.

Мактау грамотасы тексты астында ике юлга «Питрәч муниципаль районы башлыгы» сүзләре, шәхси имза һәм имзаның расшифровкасы урнаштырыла, ул имза куючы затның инициалларыннан һәм фамилиясеннән тора, алар кара төстәге хәрефләр белән басылган.

ПЕСТРЕЧИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПИТРӘЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ

# ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА



Кушымта № 2
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына
26 февраль, 2025 ел № 382

Кушымта № 3
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район башлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәгә

## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Башлыгының Рәхмәт хаты тасвирламасы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Башлыгының Рәхмәт хаты (алга таба – Рәхмәт хаты) А4 форматындагы бланктан тора.

Бланкның сурәте берьяклы, ул тыгыз, тонык кәгазьдә эшләнә. Бланкның фоны соры төстә. Бланкның периметры буйлап киңлеге 10 миллиметр булган геометрик паттерн рәвешендәге орнамент урнашкан.

Бланкның өске өлешендә уртадан 15 миллиметр арада Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы гербы урнашкан, аның зурлыгы 22*20 миллиметр тәшкил итә, ул күптөсле мөһер белән башкарылган (яшел кырлы кара кызыл битнең өске өлешендә - алтын кувшин, аның өстендә алтын әтәч тора, аяклары янында койрыклары кыскартылып утырган һәм әйләнеп киткән ике көмеш чәшке тотып тора).

Вертикаль буенча 10 миллиметр арада Питрәч муниципаль районы гербының сул һәм уң ягында өч юлда «ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» һәм «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПИТРӘЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» сүзләре урнашкан. Текст блоклары кара төстә эшләнгән, хәрефләрнең биеклеге 4 миллиметр.

Бланкның уң чигеннән горизонталь буенча 17 миллиметр һәм югары чигеннән вертикаль буенча 55 миллиметр ераклыкта «БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО» дигән язу урнашкан. Хәрефләрнең биеклеге - 10 миллиметр. Язу кызыл төстә эшләнгән.

Астарак кара төстәге 6 миллиметр (баш), 4 миллиметр (юл) биеклектәге хәрефләр белән бүләкләнүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазифасы басыла.

Тагын да түбәнрәк 10 миллиметрга кара төстәге 5 миллиметр (баш) һәм 3 миллиметр (юл) биеклектәге хәрефләр белән бүләкләнүче казанышларының кыскача тасвирламасы басыла.

Мактау грамотасы тексты астында ике юлга «Питрәч муниципаль районы башлыгы» сүзләре, шәхси имза һәм имзаның расшифровкасы урнаштырыла, ул имза куючы затның инициалларыннан һәм фамилиясеннән тора, алар кара төстәге хәрефләр белән басылган.

ПЕСТРЕЧИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПИТРӘЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ

# БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО